**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 12 сентябрь № 669

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 2 август, 366 нчы; 2010 ел, 3 февраль, 53 нче; 2011 ел, 12 октябрь, 847 нче; 2013 ел, 16 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 19 август, 599 нчы; 2015 ел, 13 апрель, 250 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу кагыйдәләренә һәм тәртибенә теркәлгән 3 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта:

җиденче абзацка «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы бурычлар хакында белешмә (Россия Федерациясе Президентының 2014 ел, 23 июнь, 460 нчы Указы белән расланган);»;

унберенче абзац үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен торак төзүчеләрне, җир кишәрлекләрен, торак төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 14 июль, 496 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 27 апрель, 290 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен җир кишәрлекләрен, торак төзүчеләрне, торак

төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

6 нчы пунктның җиденче абзацына «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшерүен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкаруы өчен кирәк булган, төзелешкә гражданнар акчасын җәлеп итүче затлардан алына торган мәгълүматлар һәм (яисә) документлар исемлеге турында» 2013 ел, 11 октябрь, 750 нче карарына теркәлгән кушымтага түбәндәге үзгәрешне кертергә:

46 нчы пунктның икенче абзацына «(Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда)» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\669.doc